Кукмара муниципаль районы
Починок-Кучук авыл җирлеге Советы

# КАРАР

14 март, 2025 ел №4

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Починок-Кучук авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Починок-Кучук авыл җирлеге Советы карары проектын хупларга (1 нче кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 28 гыйнварындагы 4 номерлы Кукмара шәһәре Советы карары нигезендә «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Починок-Кучук авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрергә.

3. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү һәм аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашуы турында» Починок-Кучук авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

Петров Геннадий Иван улы –комиссия рәисе;
Сагдиев Фаниль Абдул улы – комиссия әгъзасы;
Искакова Ирина Кисан кызы –комиссия әгъзасы.

5. Билгеләргә:

5.1. Гавами тыңлаулар үткәрү вакыты – 07.04.2025.

5.2. Гавами тыңлауларны үткәрү вакыты – 18.00 сәгать.

5.3. Үткәрү урыны – Починок-Кучук авыл мәдәният йорты бинасы, адресы: ТР, Кукмара районы, Починок Кучук авылы, Мэктеб ур., 47 .

6. Эшче төркемгә, ачык тыңлауларда кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге Советы утырышында карарга кертергә.

**7.** Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Интернет челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында http://kukmor.tatar.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Г.И. Петров

ОГРН 1021607752924
ИНН 1623001741

Починок-Кучук авыл җирлеге Советының 2025 елның 14 мартындагы 4 номерлы карарына 1 нче кушымта

Починок-Кучук авыл җирлеге Советы

КАРАР

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Починок-Кучук авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль берәмлекнең рәсми атамасы – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге, кыскартылган атамасы – Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге (текстта алга таба – җирлек).».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авылы территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы — Г.И. Петров

Починок-Кучук авыл җирлеге Советының 2025 елның 14 мартындагы 4 номерлы карарына 2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Починок-Кучук авыл җирлеге Советы карары проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проектына тәкъдимнәр Починок-Кучук авыл җирлеге Советына кертелә адресы: ТР, Кукмара районы, Починок Кучук авылы, Мэктеб ур., 46., яисә факс белән (84364) 30-2-93 кушымта итеп бирелгән үрнәк буенча төзәтмәләр таблицасы рәвешендә язма формада:

| т/б № | Статья, пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмәләрне исәпкә алып, проект тексты | Төзәтмә авторы (Ф.И.А, адресы, телефоны, эш (уку) урыны |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8 сәгать 00 минуттан 16 сәгатькә кадәр карар игълан ителгән көннән бер ай эчендә кабул ителә.

2. Гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар шәхсән яки почта аша: ТР, Починок Кучук ав., Мэктеб ур., 46 йорт (конвертта «Устав турында фикер алышу» яки «гавами тыңлаулар» дигән тамга белән), шулай ук факс буенча (84364) 30-2-93 тапшырыла.

Гаризалар гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча, эш көннәрендә 8 сәгать 00 минуттан 16 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре Починок-Кучук авыл башкарма комитеты Секретаре тарафыннан теркәлә һәм, карау өчен, Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге башлыгы урынбасарына тапшырыла.

Авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы — Г.И. Петров

ОГРН 1021607752924
ИНН 1623001741